**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИШЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАРЫ

2022 ел, 5 апрель №7

**Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлегенең башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Ишеево авыл җирлеге Башкарма комитетының «муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 елның 10 августындагы - 5 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктының икенче баганасындагы беренче абзацында «10 эш көне» сүзләрен «7 (җиде) эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

2) 3.5.1 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар запросларга җаваплар килгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга) һәм авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Ишеево авыл җирлеге**
**Башлыгы** **Р.Р. Сатдинов**